**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

28.12. 2021 ел № 18/2

Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында һәм Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү һәм урнаштыру тәртибе хакында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елның 30 июненә кадәр (бу көнне дә кертеп) Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы, Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче гражданнар, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы « Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 25 апрелендәге 46/3 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы « Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасы исемлегенә кертелгән Тукай муниципаль районы « Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче гражданнар (аларга билгеләнгәндә гражданнар керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш һәм аларны биләгәндә муниципаль хезмәткәрләр мөлкәти характердагы керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш), муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче гражданнар Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча бирелә торган мәгълүматлар белән бергә, Россия Федерациясе Президентының «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указына 1 нче кушымта

нигезендә үзләренең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының, бер үк вакытта цифрлы финанс активларын һәм башка цифрлы хокукларны, утилитар цифрлы хокукларны һәм цифрлы валютаны (алар булганда) үз эченә алган, цифрлы финанс активлары, цифрлы хокуклары турында хәбәрнамә тапшыралар.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы « Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 25 апрелендәге 46/3 номерлы карары белән расланган Муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасы биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, шулай ук муниципаль вазыйфаларны яисә Тукай муниципаль районында контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 6 һәм 8 пунктларының 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) хисап чорына (1 январьдан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр килешү (сделка) буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат, әгәр мондый килешүләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) сатып алу килешүенә кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм сатып алу килешүенә средстволар алу чыганаклары турында.».

2.2. түбәндәге эчтәлектәге 8.1 пунктын өстәргә:

«8.1. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими рәвештә башкаручы зат депутат булып сайланганнан, аңа вакантлы депутат мандаты тапшырылганнан яки даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктатканнан соң дүрт ай эчендә, шулай ук хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар башка затлар чыгымнарының һәм аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 1 өлешендә каралган килешүләр (сделка) башкарылган очракта һәр ел өчен керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирә.

Хисап чоры дәвамында мондый килешүләр төзелмәгән очракта, күрсәтелгән зат, керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү өчен махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсын (dohod.tatar.ru) кулланып, әлеге Нигезләмәгә кушымта формасы буенча хәбәрнамә җибәрү юлы белән, бу хакта Татарстан Республикасы Президентына хәбәр итә.

Әлеге пунктта каралган хәбәрнамә, шулай ук белешмәләр («Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 1 өлешендә каралган килешүләр хисап чоры дәвамында башкарылган очракта) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән срокта бирелә.»;

2.3. түбәндәге эчтәлектәге кушымтаны өстәргә:

«____________________________________________
(*муниципаль берәмлек исеме)* Советының ______ елның _____ ___________ ___ номерлы карары белән расланган ____________________________________________
*(муниципаль берәмлек исеме)* муниципаль вазыйфа биләүне дәгъвалаучы гражданнарның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм «_______________________________________________
*(муниципаль берәмлек исеме)* муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибе турында нигезләмәгә (гамәлдәге Нигезләмәнең төгәл атамасы) кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты**
____________________________________

**Хәбәрнамә**

Мин, _________________________ муниципаль районы ___________________________
*муниципаль район исеме* *авыл җирлегенең вәкиллекле органы исеме*
авыл җирлеге депутаты
________________________________________________________________________________
________________ ,
*фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда)*
«___»______________ _______туган ел, паспорт сериясе _____№_________
________________________________________________________________________________
________________ ,
*бирү датасы һәм паспорт биргән орган*

Сезгә 20__ елның 1 январеннан 31 декабренә кадәр хисап чоры дәвамында үзем, хатыным (ирем) һәм (яки) балигъ булмаган балаларым тарафыннан килешүләр башкарылмавы турында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 1 өлешендә каралган килешүләр (җир кишәрлеген, башка күчемсез милек объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләрен, пайларны), цифрлы финанс активларын, цифрлы валюта сатып алу буенча гомуми суммасы хисап чорыннан алдагы өч ел өчен үземнең һәм хатынымның (иремнең) кеременнән артып киткән килешүләр) башкарылмавы турында «Коррупциягә

каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $12^{1}$ статьясы 4.2 өлеше һәм «Муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы 4.1 өлеше нигезендә хәбәр итәм.

Әлеге мәгълүматларның дөреслеген раслыйм.

«___»___________ 20____ел

_______________________________________________

*(хәбәрнамә биргән зат имзасы)*

____________________________________________________________________________

*(хәбәрнамәне кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының (булганда) исеме һәм имзасы)».*

3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы « Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 27 сентябрендәге 26/5 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы « Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районы « Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тапшыру тәртибенә 3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча килешүгә (сделка) средстволар алу чыганаклары турында, әгәр мондый килешүләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) сатып алу килешүенә кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм сатып алу килешүенә средстволар алу чыганаклары турында мәгълүматлар.».

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Р.Ф.Адиев